**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«14» 05 2025 ел Яр Чаллы № 1530

2025 елга Тукай муниципаль районы авыл җирлекләре юлларында юл эшләре турында

«Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 21 ыевралендәге 107 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2025 елга Тукай муниципаль районы авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының урам-юл челтәрен төзү» район программасын расларга.
2. Әлеге карарны интернет челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А. Р. Хәбибуллин

**«2025 ЕЛГА ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ ЧИКЛӘРЕНДӘ УРНАШКАН ГОМУМИ ФАЙДАЛАНУДАГЫ АВТОМОБИЛЬ ЮЛЛАРЫНЫҢ УРАМ-ЮЛ ЧЕЛТӘРЕН ТӨЗҮ» ПРОГРАММАСЫ**

**Яр Чаллы шәһәре, 2025 ел**

# ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2025 елга Тукай муниципаль районы авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының урам-юл челтәрен төзү |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>Россия Федерациясе Конституциясе;<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 21 февралендәге 107 номерлы карары («Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында «Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 21 февралендәге 107 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына үзгәреш кертү хакында» үзгәрешләр белән) |
| Программаның заказчысы | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты, авыл җирлекләре Башкарма комитетлары |
| Программаны төп эшләүчеләр | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты:<br>- Тукай муниципаль районының икътисадый һәм социаль үсешенә ярдәм итү;<br>- Тукай муниципаль районы икътисады һәм халкы ихтыяжлары нигезендә урам-юл челтәрен камилләштерү һәм үстерү хисабына гражданнарның тормыш дәрәҗәсен күтәрү;<br>-юл-транспорт һәлакәтләренең авырлыгын киметү, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм аларның мөлкәтен саклауны тәэмин итү, Тукай муниципаль районы юлларында хәрәкәт итүнең куркынычсыз шартларына законлы хокукларының гарантияләрен арттыру;<br><br>Максатка ирешү шарты булып түбәндәге бурычларны хәл итү тора:<br>- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү;<br>- ел әйләнәсе халык өчен уңайлы булган автомобиль юллары челтәрен формалаштыру өчен шартлар тудыру;<br>-юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү, әйләнә-тирә мохиткә |

| | |
|---|---|
| | тискәре йогынтыны киметү һәм гражданнарга үз вакытында медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итү исәбенә халыкның гомер озынлыгын арттыру;<br>- торак пунктлар урамнарын төзекләндерү торышын яхшырту;<br>- юл инфраструктурасы объектларында хезмәт күрсәтү өлкәсен үстерү;<br>- камилләштерелгән автомобиль юллары янында җир һәм мөлкәтнең базар бәясе арту нәтиҗәсендә керемнәрне арттыру;<br>- нәтиҗәле планлаштыру хисабына районның юл хуҗалыгына чыгымнарның нәтиҗәлелеген арттыру;<br>- автомобиль транспорты хәрәкәте маршрутларының озынлыгын киметү максатында, район юл челтәрен оптимальләштерү;<br>- транспорт инфраструктурасының барлык объектларына һәм предприятиеләргә камилләштерелгән өслекле автомобиль юллары буенча керү юлларын тәэмин итү;<br>- автомобиль юлларыннан авариялелек һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауның чагыштырма күрсәткечләрен киметү;<br>- юл эшләренең сыйфатын күтәрү;<br>- автомобиль юлларының транспорт челтәрен яхшырту |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2025 ел |
| Көтелгән соңгы нәтиҗәләр | Авыл җирлекләренең урам-юл челтәре торышын яхшырту, юлларның үткәрүчәнлек сәләтен арттыру һәм экологик куркынычсызлыкны яхшырту, җирлекнең юл хуҗалыгына бүлеп бирелгән акчаларны файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру |
| Программаның төп чаралары | - Бәяләү торышы. Милек хокукы өчен документлар, кадастр һәм техник паспортлар һәм ызан эшләре өчен документлар рәсмиләштерү.<br>- Урам-юл челтәрен төзү һәм ремонтлау буенча проект-смета документациясен эшләү.<br>- Урам-юл челтәрен үстерүне муниципаль берәмлекнең шәһәр төзелеше документлары белән бәйләү.<br>- Муниципаль юл фондын формалаштыру.<br>- Торак пунктларның гамәлдәге юлларын капиталь ремонтлау һәм яңа юлларын төзү |
| Программаның ярдәмче программалары һәм төп чаралары үтәлешен оештыру өчен җаваплы затлар | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Финанслау күләме һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме 60 167 586,00 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>- район бюджеты акчалары хисабына 55 417 400,00 мең сум;<br>- ирекле калдыклар хисабына юл хәрәкәте иминлеге чаралары 4 750 186,00 мең сум |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Программа чараларының үтәлешен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты контрольдә тота |

## 1. Проблеманың эчтәлеге

Җирле әһәмияттәге автомобиль юллары муниципаль элемтәләрне тәэмин итүгә хезмәт итә, Тукай муниципаль районы чикләрендә йөкләр ташуны һәм пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә, шуның нәтиҗәсендә социаль һәм җитештерү инфраструктурасының мөһим элементы булып тора. Җирле әһәмияттәге автомобиль юллары челтәренең торышы районның социаль һәм икътисадый үсеш күрсәткечләренә турыдан-туры йогынты ясый. Программаны эшләү һәм тормышка ашыру урам-юл челтәрен, ясалма корылмаларны, юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын үстерүгә комплекслы якын килергә, аларның килешенгән үсешен һәм эшләвен тәэмин итәргә, димәк, финанс һәм матди ресурсларны нәтиҗәлерәк кулланырга мөмкинлек бирәчәк. Урам-юл челтәрен камилләштерү процессы җирлекнең социаль-икътисадый үсешенә сизелерлек йогынты ясаячак.

Соңгы вакытта халык арасында автотранспорт чаралары паркының лавина сыман үсеше күзәтелә. Соңгы елларда җирле үзидарә органнарының юлларны карап тотуга һәм төзүгә акчалары булмавына бәйле рәвештә, урам-юл челтәренең транспорт-эксплуатация торышы халыкның һәм автомобильчеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерми башлады.

Хезмәт күрсәтү өлкәсе - халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин итүнең иң мөһим өлкәләреннән берсе. Аның ярдәмендә товар тәкъдимен һәм сатып алу ихтыяҗын базар килештерүе гамәлгә ашырыла. Кулланучылар базары, бюджетка акча керү чыганакларының берсе буларак, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге икътисадының тотрыклылыгын саклауда мөһим роль уйный.

Урам-юл челтәре, ясалма корылмаларның торышы һәм юл хәрәкәте иминлеген оештыру нурам-юл челтәре, ясалма корылмаларын төзү буенча әлеге программаны эшләү буенча кичектергесез чаралар күрүне таләп итә.

Әлеге программаны эшләү һәм аны тормышка ашыру план чорында юлларны, ясалма корылмаларның торышын яхшыртырга, җәяүлеләр хәрәкәте куркынычсызлыгын арттырырга һәм авыл җирлекләре территориясендә юл-транспорт һәлакәтләре санын киметергә мөмкинлек бирәчәк.

## 2. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслауның гомуми күләме 60 167 586,00 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

- район бюджеты акчалары хисабына 55 417 400,00 мең сум;
- ирекле калдыклар хисабына юл хәрәкәте иминлеге чаралары 4 750 186,00 мең сум тәшкил итә.

## 3. Программаның төп чаралары

Бүгенге шартларда түбәндәге бурычларны хәл итү аеруча актуальләшә:

•милек хокукы өчен документлар, кадастр һәм техник паспортлар һәм ызан эшләре өчен документлар рәсмиләштерү;

•юл челтәренең төп күрсәткечләре - куркынычсызлык, юл хәрәкәте интенсивлыгы

һәм тизлеге, үткәрүчәнлек күрсәткечләре буенча транспорт-эксплуатация торышын объектив һәм оператив бәяләү;

•проект-смета документациясен эшләү;

•юл эшләрен адреслы һәм нәтиҗәле планлаштыру.

Программа авыл җирлегенең уртача сроклы юл хуҗалыгы проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән чаралар системасын күздә тота.

## 4. Программа белән идарә итүне һәм аны гамәлгә ашыру барышын тикшереп торуны оештыру

Программа чараларын тормышка ашыруны оештыру Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты, авыл җирлекләре Башкарма комитетлары тарафыннан башкарыла.

Автомобиль юлларының урам-юл челтәрен төзү буенча эшләр башкару кысаларында:

•төзелеш-монтаж эшләренең, кулланыла торган юл-төзелеш материалларының, конструкцияләрнең һәм эшләнмәләрнең сыйфатын тикшерүне тәэмин итәләр;

•торак пунктларда урамнарны карап тотуны (бу зоналарда төзелеш материалларын вакытлыча саклауга, көнкүреш чүп-чары өюләрен оештыруга юл куймау), муниципаль берәмлек чикләрендә автомобиль юлларының юл буе полосасында урнашкан күчемсез милек объектларын һәм корылмаларны, тукталышларны һәм мәйданчыкларны, башка объектларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тота.

Программа чараларын оешмалар һәм предприятиеләр тарафыннан үтәү «Дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыруга конкурслар турында» Федераль законга таянып, конкурс нигезендә контрактлар төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2025 елга Тукай муниципаль районының гомуми файдаланудагы жирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре программасына кертелгән жирле әһәмияттәге объектлар исемлеге

| № | Объект исеме | Куәте, км, пог.м, кв.м | Гамәлдәге бәяләрдә капитал кертемнәр, сумнар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Биклән авылы, Мәскәү ур. | 700 п.м., 3500 м2 | 7 984 136,9 |
| 2. | Биклән авылы, Молодежная ур. | 525 м2 | 1 173 425,1 |
| 3. | Түбән Суыксу авылы, М. Җәлил ур. | 95,3 п.м., 571,753 м2 | 2 991 452,0 |
| 4. | Боерган авылы, Мирная ур. (балалар бакчасы) | 735 м2 | 4 354 117,6 |
| 5. | Круглое Поле п., Гагарин ур. (мәктәп) | 2400 м2 | 13 907 425,8 |
| 6. | Югары Байлар авылы, (ФАП) | 60 м2, тротуар төзелеше 20 м2 | 482 509,2 |
| 7. | Иске Дөреш авылы, Ленин ур. (ФАП) | 110 м2 | 651 749,0 |
| 8. | Кече Шилнә авылы (башкарма комитет) | 150 м2, тротуар төзелеше 80 м2 | 1 317 445,7 |
| 9. | Күперле авылы, Восточная ур. (кибет) | 220 м2 | 1 862 625,3 |
| 10. | Круглое Поле п., Паровоз һәйкәлен төзекләндерү | 217 м2, тротуар төзелеше 94 м2 | 2 103 832,1 |
| 11 | Иске Абдул авылы (мәктәп) | 150 м2, тротуар төзелеше 151 м2 | 2 279 301,0 |
| 12 | Кече Шилнә авылы (мәктәп) | 745 м2, тротуар төзелеше 58 м2 | 7 089 340,9 |
| 13 | Кама п. | 220 м2, тротуар төзелеше 945 м2, яктырту җайланмасы урнаштыру | 9 220 039,6 |
| | | 1,7223 км | 55 417 400,0 |
| **2024 елга МДФ планы буенча барлыгы** | | | |
| I. | 2023 елга бюджет йөкләмәләрен үтәү | | |
| II. | Ирекле калдыклар акчалары хисабына юл хәрәкәте иминлеге буенча чаралар, шул исәптән: | | |
| | Әҗмәкәй авылы, Җиңүнең 70 еллыгы ур., "Ясалма юл тигезсезлеге" / юл билгеләре балаларның мәгариф учреждениесенә бару маршруты | Ясалма юл тигезсезлеге - 2 данә, 5.20 юл билгесе - 4 данә | 208 374,30 |
| | Яңа п. Мирная ур. һәм Җиңүнең 70 еллыгы урамы киселешe юл өстенлеге билгеләре мәгариф учрежденисенә мәктәп (балалар) автобусы хәрәкәтенең яңа маршруты. | 2.1 юл билгеләре - 2 данә, 2.4 - 2 данә | 72 041,34 |
| | Яңа п. Татарстан урамы буенча киселеш юл өстенлеге билгеләре мәгариф учрежденисенә мәктәп (балалар) автобусы хәрәкәтенең яңа маршруты | 2.1 юл билгеләре - 4 данә, 2.4 - 4 данә | 72 041,34 |
| | Бәтке авылы Үзәк, Колхозная, Школьная урамнары буйлап "Ясалма тигезсезлек" юл билгесе кую, балаларның мәгариф учрежденисенә бару маршруты | Ясалма юл тигезсезлеге - 3 данә, 5.20 юл билгесе - 6 данә | 312 559,98 |
| | Бәтке авылы Школьная урамы буенча "Сак булыгыз балалар" юл билгесе кую, балаларның мәгариф учрежденисенә бару маршруты | 2 данә | 40 256,28 |
| | "Ясалма юл тигезсезлеге" /юл билгеләре - Мирная ур., Боерган авылы, Тельман ур. Колыш авылы, балаларның мәгариф учрежденисенә бару маршруты | Ясалма юл тигезсезлеге - 2 данә, 5.20 юл билгесе - 4 данә | 865 362,70 |
| | Тукталыш павильоны - Тельман ур., Колыш авылы | 1 данә, 5.16 юл билгесе - 2 данә | |
| | «Ясалма тигезсезлек» урнаштыру, Әхмәтшин ур., 9 й., Мәскәү ур., Тукай ур., 2 й. Биклән авылы | Ясалма юл тигезсезлеге - 3 данә, 5.20 юл билгесе - 6 данә | 312 516,15 |
| | Калмаш авылы Зөфәр Галиев ур. һәм Үзәк ур. (1.23 билгесе " Сак булыгыз балалар") | 2 данә | 80 512,56 |
| | Калмаш авылы Үзәк һәм Совет урамнары (2.4 билгесе "Юл бир") | 2 данә | |
| | Сосновый Бор п. М.В. Максимов ур. буенча 2.1 билгесен "Торак зона" урнаштыру | 2 данә | 156 565,23 |
| | Сосновый Бор п. А.Ефимов ур. буенча 5.20 билгесен "Ясалма тигезсезлек" урнаштыру | 2 данә | |
| | Комсомолец п. Школьная ур. (Комсомолец урта мәктәбе янында) һәм Солнечная урамы буенча ("Петушок" балалар бакчасы янында) "Ясалма юл тигезсезлеге" билгесен урнаштыру разметка төшерү | 5.20 юл билгесе - 2 данә, асфальтта урта мәктәп һәм балалар бакчасы янында ясалма юл тигезсезлеге урнаштыру разметка белән (юлның киңлеге 4,5 м) | 104 188,98 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Круглое Поле п. Тукай ур. буенча "Ясалма юл тигезсезлеге" урнаштыру | Ясалма юл тигезсезлеге - 2 данә, 5.20 юл билгесе - 4 данә | 249 906,95 |
| | Круглое Поле п. Вокзальная ур. буенча "Җәяүлеләр кичүе" юл билгесе | 2 данә | |
| | Кече Шилнә авыл жирлегендә ясалма юл тигезсезлеге урнаштыру: | 22 данә | 1 673 149,93 |
| | Кече Шилнә авылы, Ленин, Родниковая урамнары киселешендә | 1 данә | |
| | Ильбухтино авылы, Маленков урамы һәм 2 нче Яңа тыкрык киселешенә | 1 данә | |
| | Кече Шилнә ав., Радостная ур. | 6 данә | |
| | Белоус авылы, Беляев ур. | 2 данә | |
| | Олы Шилнә авылы, Дачная ур. | 2 данә | |
| | Олы Шилнә авылы, Победа ур. | 6 данә | |
| | Ильбухтино авылы, Алтын микрорайонына борылыш (урам исемнәре белән билге) | 1 данә | |
| | Олы Шилнә авылы, Титов ур., 47 | 1 данә | |
| | Олы Шилнә авылы, Солнечная ур.,18 (борылыштан балалар мәйданчыгына кадәр) | 1 данә | |
| | Кече Шилнә авылы, Подгорная ур., 10 | 1 данә | |
| | 5.20 юл билгеләре "Ясалма тигезсезлек" Кече Шилнә авыл жирлеге | 43 данә (ясалма юл тигезсезлегенә 2 яктан) | |
| | 5.20 юл билгеләрен "Ясалма тигезсезлек" урнаштыру: Суровка авылы Чехов ур. "Элис Маркет" кибете янында, Суровка авылы Чехов ур., 93а й., Яңа Троицкий авылы, Үзәк ур., Яңа Троицкий авылы 1Ж й., Яңа Троицкий авылы, Чаллы ур., 1 й. | 5.20 юл билгесе - 8 данә. | 166 143,36 |
| | Яңа Троицкий авылы Энергетиклар ур. буенча ясалма тигезсезлекләр урнаштыру | Ясалма юл тигезсезлеге - 4 данә, 5.20 юл билгесе - 8 данә | 436 566,90 |
| | 01.01.2025 елга МДФНЫҢ фактик калдыгы буенча барлыгы | | **4 750 186,00** |